ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 20 һәм 31 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 15 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы 3-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (2005 елның 25 октябрендәге 106-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2003, № 1; 2005, № 10 (II өлеш); 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2008, № 3, № 10 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2, № 10 (II өлеш); 2011, № 5, № 11 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш); 2013, № 2 (I өлеш), № 3, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 12 (II өлеш); 2015, № 7 (I өлеш); 2016, № 4, № 7 – 8, № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш), № 37 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 57 (I өлеш); 2022, № 34 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 20 статьяның 2 өлешендәге 7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7) дәүләт органының административ регламенты (башка норматив хокукый акты) нигезендә гражданнарның һәм оешмаларның соратып алуы буенча күрсәтелә торган дәүләт хезмәт күрсәтүләре (эшчәнлек төрләре) исемлеге;»;

2) 31 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $6^1$ пункт өстәргә:

«$6^1$) дәүләт хезмәткәренең мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылуына яисә аның тарафыннан хәрби хезмәт узу турында контракт йә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә йөкләнгән бурычларны үтәүдә ихтыярый ярдәм күрсәтү хакында контракт төзелүгә бәйле рәвештә Федераль законның $53^1$ статьясында каралган гарантияләр;».

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пунктыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты 2023 елның 3 февраленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 20 декабрь
№ 92-ТРЗ